ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 2 өлештә:
7 пунктта «һәм махсуслаштырылган портлар» сүзләрен «, елга портлары, причаллар» сүзләренә алмаштырырга;
9 пунктта «вакытлы» сүзен төшереп калдырырга;
б) 3 өлешнең 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9) урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, арендага, түләүсез файдалануга бирү (әлеге статьяның 2 өлешендәге 7 һәм 9 пунктларында каралган очраклардан тыш), шулай ук урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләрен төзү (дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли парклар чикләрендә махсус саклана торган табигать территорияләре җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләреннән тыш), шул исәптән тиешле аукционнар оештыру һәм уздыру; урман фонды җирләре чикләрендәге урман кишәрлекләреннән даими (чикләнмәгән вакытка) файдалану хокукын туктату турында карарлар кабул итү, аларга карата сервитутлар билгеләү турында килешүләр төзү; урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен бирүне алдан килештерү турында карарлар кабул итү;»;

2) 7 статьяның 1 өлешендәге бишенче абзацында «вакытлы» сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең бүтән сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән гайре, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасындагы өченче абзацы, «б» пунктчасы, 2 пункты 2015 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 15 декабре
№ 118-ТРЗ